# ШУГАЛАК

Кыш ае. Көн суык.
Урамда шугалак.
Кешеләр атламый,
Баралар шугалап.

Әбиләр, бабайлар
Атлыйлар вак итеп.
Юлларга басалар
Шак итеп, сак итеп.

Малайлар шаяра –
Шуалар узынып.
Нәниләр утыра
Чанада кызыгып.

Ә кызлар чыркылдый,
Егыла язалар.
Бозлавык куркыныч –
Чыкмасын казалар!

Юлдагы машина
Тизлеген киметсен!
Мәктәпкә, бакчага
Гел имин юл илтсен!

Юл буйлап мин киләм
Бары тик шугалап.
Кыш ае. Көн суык.
Урамда шугалак.